Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XI-4**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 31 августы

Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү Тәртибен раслау турында

2020 елның 20 июлендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 236-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 20 июлендәге 216-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү Тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар көченең 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таралуын билгеләргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2021 елның
31 августындагы XI-4 номерлы
карары белән расланды

Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү
Тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрүнең әлеге Тәртибе (алга таба – Тәртип) гомуми нигезләмәләрне, шулай ук инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карау, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында аларны конкурс нигезендә сайлап алу процедураларын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

1.2. Әлеге тәртип максатлары өчен кулланыла торган төп төшенчәләр:

1) инициативалы проектлар – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә, территориянең бер өлешендә чараларны гамәлгә ашыру максатларында әлеге Тәртип нигезендә проектлар инициаторлары тарафыннан эшләнгән һәм тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүчеләр өчен җирле әһәмияттәге өстенлекле әһәмияткә ия булган проектлар яки башка мәсьәләләр, аларны хәл итү хокукы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына бирелгән;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясенең инициативалы проектлар гамәлгә ашырыла торган өлешен билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә.

2) инициативалы түләүләр – проект инициаторлары тарафыннан гражданнарның, шәхси эшкуарларның һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юридик затларның ирекле рәвештә түләнә торган һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә конкрет инициативалы проектларны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына күчерелә торган акчалары;

3) проектның инициаторлары – Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы законнарда, шулай ук әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган физик һәм юридик затлар.

## 2. Инициативалы проектларны күрсәтү (тәкъдим итү) тәртибе

2.1. Инициативалы проектларны күрсәтү проектлар инициаторлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.2. Проектларның инициаторлары булып түбәндәгеләр чыгарга мөмкин:

уналты яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә яшәүче кимендә ун граждан булган инициатива төркемнәре;

авыл торак пунктының старостасы;

үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыручы территориаль иҗтимагый үзидарә органнары;

үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар;

үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыручы юридик затлар, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар (алга таба – СОНКО (социально-ориентированные некоммерческие организации)).

2.3 Проект инициаторлары тарафыннан тәкъдим ителә торган инициативалы проектлар әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә төзелә һәм аларда Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында законнарда, шулай ук әлеге Тәртиптә билгеләнгән мәгълүматлар булырга тиеш.

2.4 Чираттагы финанс елында гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә (планлаштырыла) инициативалы проектлар агымдагы финанс елында проектларның инициаторлары тарафыннан тәкъдим ителергә мөмкин.

## 3. Инициативалы проектлар турында фикер алышу тәртибе

3.1.Инициативалы проект, аны керткәнче, җыеннарда, гражданнар җыелышында, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җыелышта, инициативалы проект турында фикер алышу, аның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яки аның бер өлешендә яшәүчеләр мәнфәгатьләренә туры килүен, инициативалы проектны гамәлгә ашыруның максатчанлыгын билгеләү, шулай ук җыен инициативалы проектларны хуплау турында карар кабул итү максатларында каралырга тиеш.

3.2.Инициативалы проектны хуплау турындагы мәсьәлә буенча гражданнарның фикерен ачыклау гражданнар арасында сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән үткәрелергә мөмкин.

3.3. Бер җыенда, бер җыелышта, гражданнарның бер конференциясендә яки гражданнардан бер сораштыру үткәргәндә берничә инициативалы проектны карау мөмкин.

3.4. Җыен, җыелышлар, конференцияләр һәм гражданнар арасында сораштыру үткәрү, аларның имзаларын җыю Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы законнар, Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 3. Инициативалы проектларны кертү тәртибе

4.1. Инициативалы проектны кертү инициатор тарафыннан проектны һәм аның составына керүче документларны, гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясе беркетмәсе, гражданнардан сорашып белешү нәтиҗәләре һәм аларның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яисә аның бер өлешендә яшәүчеләрнең инициативалы проектны хуплавын раслаучы имзалар кәгазен теркәп инициативалы проектны Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына юллау юлы белән гамәлгә ашырыла.

Проектның инициаторы физик затлар булган очракта, инициативалы проектка аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы теркәп бирелә.

4.2. Инициативалы проектны кертү турындагы мәгълүмат инициативалы проект кертелгәннән соң өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш һәм анда инициативалы проектта күрсәтелгән белешмәләр, шулай ук проект инициаторлары турында мәгълүматлар булырга тиеш.

4.3. Бер үк вакытта гражданнарга, аларны тәкъдим итү срогын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына үзләренең искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен инициативалы проект буенча тапшыру мөмкинлеге турында хәбәр ителә, ул биш эш көненнән дә ким була алмый.

Үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүче уналты яшькә җиткән кешеләр җибәрергә хокуклы.

### 5. Инициативалы проектларны карау тәртибе

5.1. Инициативалы проект әлеге Тәртипнең 2, 3 бүлекләрендә, 4 бүлегендәге 1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүгә кертелгән көннән алып 30 көн эчендә мәҗбүри каралырга тиеш.

5.2.Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле инициативалы проектны гамәлгә ашыруның нигезле, мөмкин булуы, максатчанлыгы турында бәяләмә әзерли.

5.3.Берничә инициативалы проект кертелгән очракта, шул исәптән эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирлап, конкурс нигезендә сайлап алу оештырыла һәм бу хакта проектның инициаторларына мәгълүмат җиткерелә.

5.4.Әлеге бүлекнең 6 пунктының 1-5 бүлекләрендә күрсәтелгән очракларда конкурс нигезендә сайлап алуга инициативалы проектлар кертелми.

5.5. Инициативалы проектны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) җирле бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә җирле бюджет проектын төзү һәм карау тәртибе (җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү) нигезендә инициативалы проектны хупларга һәм аның өстендә эшне дәвам итәргә.

2)инициативалы проектны хуплаудан баш тартырга һәм, инициативалы проектны хуплаудан баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, аны проект инициаторларына кире кайтарырга.

5.6 Инициативалы проектны хуплаудан баш тарту турындагы карар кабул итү түбәндәге очракларның берсендә гамәлгә ашырыла:

1) инициативалы проектны кертүнең һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициативалы проектның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары таләпләренә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры килмәве;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында кирәкле вәкаләтләр һәм хокуклар булмау сәбәпле, инициативалы проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) проектны тәэмин итү өчен чыганак булып инициативалы түләүләр тормаганда инициативалы проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләмендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында акчалар булмау;

5) инициативалы проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк ысул белән хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициативалы проектны конкурс нигезендә сайлап алуны узмаган дип тану.

5.7. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты әлеге бүлекнең 6 пунктындагы 6 пунктчасында каралган очракта, проект инициаторларына инициативалы проектны бергәләп эшләп бетерергә, шулай ук аны башка муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы яисә дәүләт органы каравына аларның компетенциясе нигезендә бирергә тәкъдим итәргә.

## 6. Инициативалы проектларны бәяләү методикасы һәм критерийлары

6.1Инициативалы проектларны бәяләү методикасы бәяләүнең билгеләнгән критерийлары буенча инициативалы проектны бәяләүнең йомгаклау бәяләмәсен исәпләү алгоритмын билгели.

6.2Инициативалы проектларны бәяләү критерийлары исемлеге һәм аларның балл кыйммәтләре әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы белән билгеләнә.

6.3Инициативалы проектны бәяләү һәр инициативалы проект буенча аерым гамәлгә ашырыла.

6.4Һәр критерий буенча инициативалы проектны бәяләү балларда билгеләнә.

6.5Инициативалы проектның максималь йомгаклау бәясе 100 балл, минимале – 0.

6.6Конкурс сайлап алуын узган булып йомгаклау бәясе нәтиҗәләре буенча 50 һәм аннан да күбрәк балл җыйган инициативалы проектлар санала.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында конкурс нигезендә сайлап алынган барлык инициативалы проектларны тормышка

ашыру өчен каралган бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта иң күп балл җыйган инициативалы проектлар санала, аларны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты хисабына гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә мөмкин.

6.7. Инициативалы проектка йомгак бәя түбәндәге формула буенча исәпләнә::

Ик = (П(ПКОкі)) х (∑(Ркg)),

биредә:

Ик – әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада күрсәтелгән критерийларны үтәүне исәпкә алып исәпләнгән инициативалы проектның йомгак бәясе;

Кі – әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән “гомуми критерийлар” төркеменә керүче критерийлар күплеге.

kі критерийларының һәркайсы 0 яки 1 кыймматен кабул итәргә мөмкин;

П(ПКОкі) – “Конкурс сайлавын узу критерийлары” төркеменә керә торган һәр критерий буенча проектка бирелгән баллар тапкырчыгышы;

Кg – әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән “Рейтинг критерийлары” төркеменә керүче критерийлар күплеге;

∑(Ркg) – инициативалы проектка "Конкурс сайлавын узу критерийлары" төркеменә керә торган һәр критерий буенча баллар суммасы.

kg критерийларының һәркайсы әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән күрсәткечләр чикләрендә критерийны үтәү дәрәҗәсенә туры килә торган кыйммәт алырга мөмкин.

Тәртипкә 1 нче кушымта

Инициативалы проект

«____»___________, 20__ел

| № п/п | Инициативалы проектның гомуми сыйфатламасы | Мәгълүматлар |
|---|---|---|
| 1. | Инициативалы проектның аталышы | |
| 2. | “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларны үтәүгә инициативалы проект юнәлдерелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр яисә Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән башка мәсьәләләр | |
| 3. | Инициативалы проектны тормышка ашыру территориясе | |
| 4. | Инициативалы проектның максаты һәм бурычлары | |
| 5. | Инициативалы проектны тасвирлау (проблеманы тасвирлау һәм аның актуальлеген (кискенлеген) нигезләү, аны хәл итү буенча тәкъдимнәрне, инициативалы проектны гамәлгә ашыру чараларын тасвирлау) | |
| 7. | Инициативалы проектны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр | |
| 8. | Финанслау тәмамланганнан соң инициативалы проектның алга таба үсешен тасвирлау (файдалану, | |

| | | |
|---|---|---|
| | эчтәлек һ.б.ш.) | |
| 9. | Турыдан-туры иминлек (муллык) алучылар (благополучательләр) саны (кеше) (турыдан-туры иминлек (муллык) алучылар санын билгеләү механизмын күрсәтергә) | |
| 10. | Инициативалы проектны тормышка ашыру вакыты | |
| 11. | Инициатор турында мәгълүмат проекта (Ф.И.А.и. (физик затлар өчен), аталышы (юридик затлар өчен) | |
| 12. | Инициативалы проектның гомуми бәясе | |
| 13. | Инициативалы проектны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары | |
| 13. | Проект инициаторы тарафыннан тәэмин ителә торган инициативалы түләүләр күләме, шул исәптән: | |
| 13.1. | Гражданнар акчалары | |
| 13.2. | Юридик затларның, шәхси эшкуарларның акчалары | |
| 14. | Проект инициаторы тарафыннан тәэмин ителә торган акчалата булмаган кертемнең күләме, шул исәптән: | |
| 14.1. | Гражданнарның акчалата булмаган кертеме (ихтыярый мөлкәти катнашу, хезмәт белән катнашуы) | |
| 14.2. | Юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның (ихтыярый мөлкәти катнашуның, хезмәт белән катнашуның) акчалата булмаган кертеме | |

Проектның инициаторы (-лары)
(Инициатор вәкиле) ____________________ Ф.И.А.и.
(имза)

Кушымталар:

1. Инициативалы проектның фаразланган бәясен исәпләү һәм нигезләү һәм (яки) проект-смета (смета) документлары.
2. Инициативалы түләүләрне һәм (яисә) ихтыярый мөлкәти катнашуны тәэмин итү һәм (яисә) инициативалы проектны тормышка ашыруда проект инициаторларының хезмәт белән катнашуы буенча йөкләмәләре булган проект инициаторы (инициатор вәкиле) тарафыннан имзаланган гарантияле хат.
3. Проект инициаторының вәкаләтләрен раслый торган документлар: паспортның күчермәсе, ышанычнамәнең (кирәк очракта) күчермәсе, җитәкчене билгеләү турында карар, уставның күчермәсе һәм вәкаләтләрне раслый торган башка документлар.
4. Инициативалы проектка (инициативалы проектны визуальләштерү чараларын кулланып) презентация (тәкъдим итү) материаллары.
5. Кирәк булганда өстәмә материаллар (сызымнар, макетлар, график материаллар һәм башкалар).
6. Проект инициаторының (инициатив төркем вәкиленең) шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

Тәртипкә 2 нче кушымта

Инициативалы проектны бәяләү критерийлары

| Критерий № ы | Критерийның /критерийлар төркеменең аталышы | Критерий буенча баллар |
|---|---|---|
| 1. | Конкурста сайлап алуны узу критерийлары, (ПКОк) | |
| 1.1. | Инициативалы проектны тормышка ашыру чаралар үткәрүне, бары тик түбәндәге мәнфәгатьләргә генә хезмәт иткән объектларны төзүне (реконструкцияләүне), ремонтлауны, төзекләндерүне күздә тота:<br>- хосусый коммерция эшчәнлеген (шәхси предприятиеләр, барлар, рестораннар һ.б.);<br>- дини оешмаларны (чиркәүләр, мәчетләр һ.б.);<br>-аерым этник төркемнәрнең. | |
| | әйе | 0 |
| | юк | 1 |
| 1.2. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет акчалары суммасы 1 500 мең сумнан артып китә. | |
| | әйе | 0 |
| | юк | 1 |
| "Конкурс сайлап алуын узу критерийлары" нәтиҗәләре: | "Проектны конкурс нигезендә сайлап алуны узу критерийлары" төркеменә кергән һәр критерий буенча проектка бирелгән баллар тапкырчыгышы | |
| 2. | Рейтинг критерийлары, (Рк) | |
| 2.1. | Инициативалы проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге: | |
| 2.1.1. | Инициативалы проектны тормышка ашыруның иҗтимагый файдалылыгы | |
| | проект Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүчеләр өчен югары социаль, мәдәни, ял итү һәм башка иҗтимагый файдасы булуы ягыннан бәяләнә:<br>актив гражданлык позициясен формалаштыруга, сәламәт яшәү рәвеше булдыруга ярдәм итә, әхлак, толерантлык, башка социаль мөһим сыйфатларны тәрбияләүгә юнәлдерелгән (чаралар, акцияләр, форумнар);<br>социаль өлкә муниципаль объектларын төзүгә, үстерүгә һәм ремонтлауга юнәлтелгән;<br>иҗтимагый инфраструктура объектларын төзүгә, үстерүгә һәм ремонтлауга, рекреацион зоналарны, социаль җәлеп итү нокталарын, халык күпләп ял итә торган урыннарны, мәдәни мирас объектларын төзү һәм төзекләндерүгә юнәлдерелгән; | 5 |

| | | |
|---|---|---|
| | җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзүгә (реконструкцияләүгә), капиталь ремонтлауга һәм ремонтлауга юнәлдерелгән. | |
| | проект иҗтимагый файдасы булмаган буларак бәяләнә. | 0 |
| 2.1.2. | Проблеманың актуальлеге (кискенлеге): | |
| | бик югары – проблема халык тарафыннан кискен дип бәяләнә, проблеманы хәл итү халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү шартларына ярдәм итү һәм саклап калу өчен кирәк. | 8 |
| | югары – проблема халык тарафыннан мөһим дип бәяләнә, аны хәл итмәү тормыш сыйфатына тискәре йогынты ясаячак. | 7 |
| | уртача – проблема халык тарафыннан актуаль дип бәяләнә, аны хәл итү тормыш сыйфатын яхшыртуга китерергә мөмкин | 6 |
| | түбән – халык тарафыннан актуаль дип бәяләнми, аны хәл итү тормыш сыйфатын яхшыртуга китерми. | 0 |
| 2.1.3. | Инициативалы проектны тормышка ашырудан турыдан - туры иминлек (муллык) алучылар саны: | |
| | 500 кешедән артык | 4 |
| | 250 дән 500 кешегә кадәр | 3 |
| | 50 дән 250 кешегә кадәр | 2 |
| | 50 кешегә кадәр | 1 |
| 2.1.4. | Бер турыдан-туры иминлек (муллык) алучыга исәпләгәндә инициативалы проектның бәясе: | |
| | 250 сумга кадәр | 15 |
| | 250 сумнан алып 500 сумга кадәр | 14 |
| | 500 сумнан алып 750 сумга кадәр | 13 |
| | 750 сумнан алып 1000 сумга кадәр | 12 |
| | 1000 сумнан алып 1500 сумга кадәр | 11 |
| | 1500 сумнан алып 2000 сумга кадәр | 10 |
| | 2000 сумнан алып 2500 сумга кадәр | 9 |
| | 2500 сумнан алып 3000 сумга кадәр | 8 |
| | 3000 сумнан алып 3500 сумга кадәр | 7 |
| | 3500 сумнан алып | 6 |
| 2.1.5. | Инициативалы проект нәтиҗәләрен карап тоту (хуплау, ярдәм итү) максатларында алдагы чорларда өстәмә бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру зарурилыгы | |
| | юк | 5 |
| | әйе | 0 |
| 2.1.6. | Инициативалы проектны тормышка ашыру вакыты | |
| | 1 календарь елга кадәр | 4 |
| | 2 календарь елга кадәр | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| | 3 календарь елга кадәр | 2 |
| | 3 календарь елдан артык | 1 |
| 2.1.7. | Инициативалы проект нәтиҗәләренең “Яшәү вакыты” | |
| | 5 елдан алып | 4 |
| | 3 елдан алып 5 елга кадәр | 3 |
| | 1 елдан алып 3 елга кадәр | 2 |
| | 1 елга кадәр | 1 |
| 2.2. | Инициативалы проектның үзенчәлекле булуы, инновациялелеге | |
| 2.2.1. | Инициативалы проект идеясенең үзенчәлекле булуы, гадәти булмавы | |
| | әйе | 5 |
| | юк | 0 |
| 2.2.2. | Инновацион технологияләрне, яңа техник чишелешләрне куллану | |
| | әйе | 5 |
| | юк | 0 |
| 2.3. | Инициативалы проектны конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен документлар әзерләү сыйфаты | |
| 2.3.1. | Гаризага теркәп бирелгән проект-смета (смета) документлары булу (объектларны төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау, ремонтлау буенча) | |
| | әйе яки проект-смета (смета) документларына ихтыяҗ юк | 10 |
| | юк | 0 |
| 2.3.2. | гаризага теркәлгән презентация материаллары булу | |
| | әйе | 10 |
| | юк | 0 |
| 2.4. | Инициативалы проектны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда җәмәгатьчелекнең катнашуы | |
| 2.4.1. | Гражданнарның инициативалы проектны финанслашу дәрәҗәсе | |
| | инициативалы проект бәясенең 20 % ыннан башлап | 5 |
| | инициативалы проект бәясенең 15 % ыннан башлап 20 % ына кадәр | 4 |
| | инициативалы проект бәясенең 10 % ыннан башлап 15 % ына кадәр | 3 |
| | инициативалы проект бәясенең 5 % ыннан башлап 10 % ына кадәр | 2 |
| | инициативалы проект бәясенең 5 % ына кадәр | 1 |
| 2.4.2. | Юридик затлар, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан инициативалы проектны финанслашу дәрәҗәсе | |
| | инициативалы проект бәясенең 20 % ыннан башлап яисә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан инициативалы проект бәясенең 5% ыннан алып финанслашу | 5 |

| | | |
|---|---|---|
| | инициативалы проект бәясенең 15% тыннан алып 20 % ына кадәр | 4 |
| | инициативалы проект бәясенең 10% тыннан алып 15 % ына кадәр | 3 |
| | инициативалы проект бәясенең 5% тыннан алып 10 % ына кадәр | 2 |
| | инициативалы проект бәясенең 5 % ына кадәр | 1 |
| 2.4.3. | Инициативалы проектны тормышка ашыруда гражданнарның мөлкәти һәм (яки) хезмәт белән катнашу дәрәҗәсе | |
| | инициативалы проект бәясенең 20 % ыннан башлап | 5 |
| | инициативалы проект бәясенең 15% ыннан алып 20 % ына кадәр | 4 |
| | инициативалы проект бәясенең 10% ыннан алып 15 % ына кадәр | 3 |
| | инициативалы проект бәясенең 5% ыннан алып 10 % ына кадәр | 2 |
| | инициативалы проект бәясенең 5 % ына кадәр | 1 |
| 2.4.4. | Юридик затларның, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның һәм шәхси эшкуарларның инициативалы проектны тормышка ашыруда мөлкәти һәм (яки) хезмәт белән катнашу дәрәҗәсе | |
| | проект бәясенең 20% ыннан яки социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның хезмәт белән катнашуы инициативалы проект бәясенең 5% ыннан алып | 5 |
| | инициативалы проект бәясенең 15% ыннан алып 20 % ына кадәр | 4 |
| | инициативалы проект бәясенең 10% ыннан алып 15 % ына кадәр | 3 |
| | инициативалы проект бәясенең 5% ыннан алып 10 % ына кадәр | 2 |
| | инициативалы проект бәясенең 5 % ына кадәр | 1 |
| 2.4.5. | халыкның инициативалы проектны хуплау (ярдәм итү) дәрәҗәсе | |
| | инициативалы проект тормышка ашырыла торган территориядә җирлек халкы санының 15 % ыннан алып | 5 |
| | инициативалы проект тормышка ашырыла торган территориядә җирлек халкы санының 10 % ыннан алып 15% ына кадәр | 4 |
| | инициативалы проект тормышка ашырыла торган территориядә җирлек халкы санының 5 % ыннан алып 10% ына кадәр | 3 |
| | инициативалы проект тормышка ашырыла торган территориядә җирлек халкы санының 1 % ыннан алып 5% ына кадәр | 2 |
| | инициативалы проект тормышка ашырыла торган территориядә җирлек халкы санының 1% ына кадәр | 1 |

| | |
|---|---|
| "Рейтинг критерийлары" нәтиҗәләре: | “Конкурс сайлавын узу критерийлары” төркеменә керә торган һәр критерий буенча инициативалы проектка бирелгән баллар суммасы |
| Инициативалы проектны бәяләү | “Конкурс сайлавын узу критерийлары” нәтиҗәләре,”"Рейтинг критерийлары” нәтиҗәсе |